СОВЕТ
ВЕРХНЕТАКЕРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ТӘКЕРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

24 июнь 2025 ел

КАРАР

№ 1

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлеге Советы бишенче чакырылыш депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Югары Тәкермән авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының бишенче чакырылыш Югары Тәкермән авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Минзәлә» газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Югары Тәкермән авыл җирлеге башлыгы А.А. Шәрипова